ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 июня 2025г. № 4774

Даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртүләр маршруты картасы дубликатын бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль законның 29.2 статьясы, шәһәр Уставының 9, 41 статьялары, Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 номерлы Карары белән расланган «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртүне оештыру тәртибенең 7 өлешенең 4.1 пунктчасы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртүләр маршруты картасы дубликатын бирү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan/ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 27 июнендәге
4774 номерлы карарына
кушымта

Даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртүләр маршруты картасы дубликатын бирү тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын һәм даими йөртүләр маршруты картасы дубликатын бирү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 220–ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә эшләнде.

2. Даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык дубликатын (алга таба – таныклык дубликаты) һәм даими йөртүләр маршруты картасы дубликатын (алга таба - маршрут картасы дубликаты) бирүне гамәлгә ашыручы вәкаләтле орган булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе (алга таба - вәкаләтле орган) тора.

3. Таныклык дубликаты һәм маршрут картасы дубликаты, даими йөртүләрнең муниципаль маршруты буенча йөртүләрне гамәлгә ашыру турында таныклык яки даими йөртүләр маршруты картасы югалган яисә алар бозылган очракта, вәкаләтле орган тарафыннан бирелә.

2 бүлек. Таныклык дубликатын һәм маршрут картасы дубликатын бирү тәртибе

4. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта, даими йөртүләрнең муниципаль маршрутлары буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыручы юридик зат, шәхси эшмәкәр яки гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы (алга таба – гариза бирүче) таныклык дубликатын яки маршрут картасы дубликатын бирү өчен, ирекле рәвештә төзелгән гариза белән вәкаләтле органга мөрәҗәгать итә. Гариза кергән көнне ул вәкаләтле орган тарафыннан теркәлә.

5. Гариза түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

1) исеме, урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме һәм, әгәр булса, атасының исеме, яшәү урыны (шәхси эшмәкәр, гади ширкәт шартнамәсенең вәкаләтле катнашучысы өчен), салым түләүченең идентификация номеры, почта адресы, элемтә телефоннары.

Гариза бирүче исеменнән аның вәкиле эш иткән очракта, гаризага вәкилнең таныклык дубликатын яки маршрут картасы дубликатын алуга хокукын раслый торган ышаныч язуының күчермәсе теркәлә;

2) даими йөртүләр муниципаль маршрутының теркәү номеры һәм исеме;

3) элек бирелгән таныклыкның яки маршрут картасының сериясе һәм номеры;

4) таныклыкның яки маршрут картасының югалу яисә бозылу сәбәпләре;

5) таныклык яки маршрут картасы дубликатын алу ысулы (кулга тапшырып яки күрсәтелгән почта адресы буенча белдерү кәгазе булган заказлы хат белән).

6. Бозылган очракта, яраксыз хәлгә килгән таныклык яки маршрут картасы гаризага теркәлә.

7. Таныклык дубликатын яки маршрут картасы дубликатын бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) гаризада тулы булмаган яисә дөрес булмаган мәгълүматларны күрсәтү;

2) әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган шартларны бозу.

8. Әлеге тәртипнең 7 пунктында каралган нигезләр булганда, вәкаләтле орган гаризаны теркәгән көннән башлап 10 эш көне эчендә, мондый кире кагуның сәбәпләрен нигезләп, гариза бирүчегә таныклык дубликатын яки маршрут картасы дубликатын бирүдән баш тарту турында белдерү кәгазе җибәрә. Белдерү кәгазе гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

9. Әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган нигезләр булмаганда, вәкаләтле орган гаризаны теркәгән көннән башлап 10 эш көне эчендә, таныклык дубликатын яки маршрут картасы дубликатын рәсмиләштерә һәм гаризада күрсәтелгән ысул белән җибәрә.

10. 220-ФЗ номерлы Федераль законның 27 статьясындагы 3 өлеше һәм 28 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, таныклык дубликаты яки маршрут картасы дубликаты, формалары транспорт өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслаган бланкларда бирелә.

11. Таныклык дубликаты яки маршрут картасы дубликаты бланкларына вәкаләтле орган тарафыннан бирелеп, югалган яки бозылган таныклык һәм маршрут картасы бланкларында булган мәгълүматларга тәңгәл мәгълүматлар кертелә. Таныклык дубликаты яки маршрут картасы дубликаты бланкларын тутырганда түбәндәге язулар күрсәтелә:

таныклык дубликаты бланкында - «000000 серияле 000000 номерлы ТАНЫКЛЫК ДУБЛИКАТЫ» аерым юлда, үзәк буенча тигезләп;

маршрут картасы дубликаты бланкында - «000000 серияле 000000 номерлы МАРШРУТ КАРТАСЫ ДУБЛИКАТЫ» аерым юлда, үзәк буенча тигезләп.

Әлеге пунктта күрсәтелгән таныклык дубликатындагы яки маршрут картасы дубликатындагы язулар вәкаләтле вазыйфаи зат имзасы һәм вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы мөһере белән таныклана.

12. Бирелгән таныклык дубликатының һәм маршрут картасы дубликатының күчермәләре вәкаләтле органда саклана.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева